МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.04.2023 Казан ш. № 246-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.08.2022 № 488-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле боерам:

1. “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.08.2022 № 488-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге

боерык белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. 2023 елда Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә 2022 елда җир мөнәсәбәтләрен көйләү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге карары (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 30 декабрендәге № 2536 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән билгеләнгән үзенчәлекләрне искә алып тормышка ашырылуын гамәлгә куярга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
17.04.2023 № 246-пр
боерыгы белән расланды

“Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.08.2022 № 488-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

2 бүлектә:

Түбәндәге эчтәлекле 2.3.8, 2.3.9, 2.3.10 пунктлар өстәргә:

«2.3.8. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карарның (җир кишәрлеген бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карар) реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карарны (җир кишәрлеге бирүне алдан килештерүдән баш тарту турында карарны) электрон имза белән имзалаганда).

2.3.9. Җир кишәрлеген милеккә бирү турында карар (җир кишәрлеген арендага бирү турында карар, җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту

турында карар, җир кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар) реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җир кишәрлеген милеккә бирү турында карарны, җир кишәрлеген арендага бирү турында карарны, җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турында карарны, җир кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карарны электрон имза белән имзалаганда).

2.3.10. Сату-алу шартнамәсе (аренда шартнамәсе) реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (сату-алу шартнамәсен (аренда шартнамәсе) электрон имза белән имзалаганда)»;

2.4.1 пунктта «19 көн» «15 көн» сүзләре белән алыштырырга;

2.4.2 пунктта «19 көн» «15 көн» сүзләре белән алыштырырга;

2.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза МФЦ аша тапшырган икән, Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте гариза һәм документлар регистрацияләнгәннән соң 15 эш көне эчендә күрсәтелә, шулай ук, МФЦ Регламенты белән каралган срок та искә алына.»;

2.4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче күрсәткән ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт

хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.

Гариза бирүченең аренда шартнамәсе яки җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсен имзалау вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.»;

2.4.7 пунктта «45» сүзен «35» сүзе белән алыштырырга;

2.8.3 пунктта «45» сүзен «35» сүзе белән алыштырырга;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган сүзе белән алыштырырга;

2.14.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибенә мөрәҗәгать итергә каршылык тудырмый.»;

3 бүлектә:

3.4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацын «әлеге Регламентның» дигән сүзләрдән соң «2.6.1» цифрлары белән тулыландырырга;

3.6.2 пунктта «Бердәм портал» сүзен төшереп калдырырга;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

3.6.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.3. Бүлек белгече Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Бүлек белгече карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Тикшерү нәтиҗәсендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булу шартлары үтәлмәве ачыклаеса, документларны кабул итүдән баш тарту № 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Бүлек белгече “Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау” административ процедурасын башкаруга күчә.»;

3.6.2.4 пунктны «Башкару» сүзеннән соң «аерым» сүзе белән тулыландырырга;

3.6.3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән язмача баш тарту, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.»;

3.7.3 пунктта «45» сүзен «35» сүзе белән алыштырырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау.»;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.

Дәүләт хезмәтен туктатып тору турында нигезләр булмаса, Бүлек белгече контроль бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач, “Гаризаның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыганнан үтү битен” (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) тутыра һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар юллый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле соралган документлар исемлеге:

Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать ителсә:

1. Җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә, ТР буенча Росреестрдан.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә, ТР буенча ФСХИдан;

Министрлыкка дәүләт хезмәте максатларында җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә милеккә, арендага бирү турында мөрәҗәгать ителсә:

1. Җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә, ТР буенча Росреестрдан.

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә, ТР буенча ФСХИдан;

3. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган документлар, дәүләт хакимиятнең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар регистрацияләнгән бер эш көнендә үтәлә.»;

3.8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.2. Министрлыкка җир кишәрлеген РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә бирүне алдан килештерү турында гариза керсә, җир кишәрлеге ясаласы җир кишәрлеге схемасы «Россия Федерациясе Җир Кодексын гамәлгә кертү турында» № 137-ФЗ Федераль законның $3^5$ статьясы нигезендә килештерелергә тиеш булган очракларда, Бүлек белгече ведомоствоара арадашлык системасы аша электрон формада территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү өчен Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы) юллый һәм җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү өчен юллау турында гариза бирүчегә хәбәр ителүен тәэмин итә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүче тапшырган җир кишәрлегенең урнашу схемасының килештерү өчен ТР Урман хуҗалыгы министрлыгына юллануы, җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү өчен юллау турында гариза бирүчегә юлланган хәбәр.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар кергәч бер эш көне эчендә үтәлә.»;

3.8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 3.8.1 пункты белән каралган документлар, әлеге Регламентныың 2.6.7 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында

ведомоствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.»;

Түбәндәге эчтәлекле 3.8.4, 3.8.5, 3.8.6 пунктлар белән тулыландырырга:

«3.8.4. ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы белгечләре әлеге Регламентның 3.8.2 пунктында күрсәтелгән запрос нигезендә җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында хәбәр бирәләр яки килештерүдән баш тарту турында белдерәләр.

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында яки килештерүдән баш тарту турында белдерү әзерләү һәм юллау срогы № 137-ФЗ Федераль законның $3^5$ статьясының 4 пункты нигезендә Җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында Министрлыктан запрос килгәннән соң 20 календарь көнне тәшкил итә.

Процедура нәтиҗәсе: ТР Урман хуҗалыгы министрлыгына юлланган җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында яки килештерүдән баш тарту турында белдерү.

3.8.5. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.7 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.

3.8.6. Министрлыкның структур бүлекчәләре арасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм Министрлык карамагында булган мәгълүматны алмашу, шул исәптән, электрон формада, Татарстан Республикасы Җир һәм

мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкция нигезендә алып барыла.»;

3.9.2.8 пунктның икенче абзацында «ике эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.9.3.1 пунктның җиденче абзацында «ике эш көне эчендә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.9.3.3 пунктның алтынчы абзацында «өч көн» сүзен «ике көн» сүзе белән алмаштырырга;

3.10.1 пунктның беренче абзацында «Нәтиҗәсе бирелә» сүзләрен «Нәтиҗәсен бирү» сүзләре белән алмаштырырга;

Регламентның 5 нче кушымтасында «Бердәм портал,» сүзен төшереп калдырырга.